ZAMAN
ТАТАРСТАН
ФАРКЛЫ ГӘЗИТ 16—30 ИЮНЬ 1993 ЕЛ № 4 БӘЯСЕ 5 СУМ

ТАҢСУ ЧИЛЛӘР — ТӨРКИЯНЕҢ ПРЕМЬЕР-МИНИСТРЫ

Төрки җөмһүриятләрдә хөкүмәт башында беренче хатын-кыз

Кем ул Таңсу Чилләр?

1946 ЕЛДА Истанбулда дөньяга килде. Анасы Муаззәз, атасы Хөсәен Нәҗати. 1963 елда Истанбулдагы Американ Кызлар Колледжендә укый башлады, соңыннан Роберт Колледженың икътисад бүлегенә күчеп, аны 1967 елда тәмамлап чыкты. Шуннан соң белем алуны АКШта дәвам итте. Әүвәл Нью Һәмпшир университетында ике ел укып һәм эшләп, соңра Коннектикут һәм Йель университетларында кандидатлыгын яклады. 1974—75 елларда Франклин әнд Маршалл Колледжендә ярдәмче профессор булып эшләде. 1976 елдан башлап Истанбулның Бугаз эче университетында икътисад һәм идарә фәннәре факультетында мөгаллимлек эшен башкарды, профессор булды. 1990 елда Тугры Юл Партиясенә керде, партиянең мәҗлес әгъзасы һәм генераль секретаре урынбасары вазифаларын башкарып килде. 1991 елда Төркия Бөек Милләт Мәҗлесенә депутат итеп сайланды. Тугры Юл Партиясе һәм Социалистик Халык Партиясе тарафыннан корылган коалицион хөкүмәттә икътисад өчен җаваплы премьер-министр урынбасары (дәүләт министры), бераздан икътисад министры дәрәҗәсенә күтәрелде. ТЮПның генераль секретаре Сөләйман Дәмирәл президент булып сайланганнан соң, бушап калган генераль секретарь һәм премьер-министр постларына сайлану өчен Таңсу Чилләрнең дә кандидатлыгы күрсәтелде. Төркия тарихына беренче хатын-кыз премьер-министр буларак керәчәк Таңсу Чилләр 500 миллиард төрек лира кыйммәтендә байлыкка ия. Ире һәм ике баласы бар.

Анкара (Заман). Тугры Юл партиясенең (ТЮП) гадәттән тыш конгрессы Төркиянең яңа премьер-министрын сайлап куйды. Беренче турда делегатларның 574 тавышын яулап алган профессор Таңсу ханым Чилләр, башка кандидатлар Исмәт Сәзгин белән Көксал Топтан 320 һәм 212 тавыш җыйганнан соң көндәшлек итүдән баш тарткач, сайлауның икенче турында 933 тавыш җыеп Тугры Юл партиясенең генераль секретаре һәм шулай ук Төркия тарихында беренче хатын-кыз премьер-министр булды.

Шулай итеп, Дәмирәл Чанкая Сараена президент сыйфатында кергәннән соң Тугры Юл партиясе лидерлыгы өчен башланып киткән ярыш Анкараның Ататөрек Спорт Сараенда нокталанды. 3 кандидат катнашы белән башланган сайлаулар, ниһаять, партия рәисе һәм бер үк вакытта хөкүмәт башлыгы вазифасын алачак кешене көн яктысына чыгарды.

ТЮПның гадәттән тыш җыены 10 сәгать 35 минутта ачылды. Гомуми Идарә әгъзасы, Чанаккала депутаты Хәмди Үчпынарлар чыгышыннан соң президиумның рәисе итеп бертавыштан Али Наили Әрдәм сайланды.

10 сәгать 45 минутлар тирәсендәрәк залга хатыны белән бергә Көксал Топтан кергәндә аны «Премьер-министр Топтан!» дип кычкырып каршы алдылар, өстенә конфетти сибелде. Делегатларны сәламләгәннән соң, Топтан урынына утырды.

Истанбул депутаты Таңсу Чилләр 11 сәгать 20 минутта залга килеп керде һәм шулай ук «Премьер-министр Чилләр!» дигән тавышларга күмелде. Чилләр залга кергәч, аның тарафдарлары куптарган гөрелте аркасында трибунада булган ТЮПның вакытлы генераль секретаре Гөлхан үзенең нотыгын өзәргә мәҗбүр булды.

11 сәгать 49 минутта җыен уза торган залга генераль секретарьлыкка өченче кандидат Исмәт Сәзгин белән дәүләт министры Җавит Чаглар килеп керделәр. Сәзгин яклылар «Премьер-министр Сәзгин!» дигән лозунглар кычкырып аңа булышлык итәргә әзер торуларын күрсәттеләр.

Шуннан соң президиум рәисе Али Наили Әрдәм генераль секретарь сайлауларына Истанбул депутаты Таңсу Чилләр, Бартын депутаты Көксал Топтан һәм Айдын депутаты Исмәт Сәзгиннәрнең катнашачакларын белдерде. Президиум, аңа кергән бер тәкъдимдә күрсәтелгәнчә, кандидатларның чыгышларын 45 минут белән чикләргә, дигән сүз белән чыккан булса да, делегатларның күбесенең нотыклар 30 минутлык булсын, дигән фикере өстенлек казанды. Тагын бер тәкъдим буенча, чыгышлар тәмамлану белән үк сайлау процедурасына керешү карары кабул ителде.

Тавыш бирү нәтиҗәләреннән чыгып, беренче сүз Таңсу Чилләргә бирелде. Ул, җыенның тарихи бер вакыйга булганын күрсәтеп, ТЮП әгъзаларының үз ирекләре белән рәисләрен сайлаячакларына ышануын әйтте. Үзенең сайлауда җиңеп чыгуы очрагында Дәмирәл тәҗрибәсеннән файдаланачагын ассызыклап сөйләгән Чилләр, «мине сайласагыз, җирле хакимият органнары сайлауларында җиңү казаначагыбызны вәгъдә итәм», дип сүзен дәвам итте. Чилләр, чыгышында Ататөрек, Мәндәрәс һәм үткәннәрдәге башка атаклы дәүләт шәхесләрнең исемнәрен искә алды. «Хәзер бер бөек төрек дәүләт затының исемен әйтәчәкмен, горурланып әйтәчәкмен. Ул исемне исегезгә төшергәндә, җир тетрәр. Ул исем — тугызынчы президентыбыз Сөләйман Дәмирәл» дигән сүзләре алкышларга күмелде. «Бүген бирердә атабыз юк. Әмма шуңа карамастан ант эчәбез, аның хезмәтләрен мәңгегә дәвам иттерәчәгебезгә ант эчәбез», диде Чилләр.

БЕРЕНЧЕ ТУР НӘТИҖӘЛӘРЕ:	
Таңсу ЧИЛЛӘР	— 574
Исмәт СӘЗГИН	— 320
Көксал ТОПТАН	— 212
ИКЕНЧЕ ТУР НӘТИҖӘСЕ:	
Таңсу ЧИЛЛӘР	— 933

Үзенең чыгышында Таңсу Чилләр еш-еш дингә дә кагылып китте, «Коръән һәм азан безнең өчен даимән мөкатдәс булып калачак. Милли байрагыбыз һәм илебез бәгъребезнең түрендә булачак. Төркиягә булган мәхәббәтебез бездән һичкайчан аерылмаячак», дип сөйләде.

Таңсу Чилләр, җирле сайлауларда да җиңәчәкләренә ышанган кебек, гомуми сайлауларда да өстен чыгачакларына инануын әйтте. Ул, шулай ук һәм Төркиянең һәм Тугры Юл Партиясенең үзгәрешләргә мохтаҗ булуларын, бу үзгәрешләрне керткән чакта моңа һичбер көч-куәтнең каршы тора алмаслыгы турында сөйләде. Чилләр, киләчәкнең йә элекке заман кебек калуы йә үзгәрешләр дәвере булуы делегатларның тавыш бирүләренә, аларның кайсы юлны өстен күрүләренә бәйле икәнен әйтеп үтте.

Чилләр Босния — Һерсеговина, Азәрбайҗан һәм Германиядәге вакыйгаларны да телгә алып, җиңү казануы тәкъдирдә халыкара тәүге сәяхәтен Германиягә оештырачагы хакында сөйләде.

Таңсу Чилләрдән соң «Төркия синең белән горурлана!» дигән авазлар астында менбәргә Милли Мәгариф министры Көксал Топтан менде һәм кыска вакыт эчендә залдагыларның дикъкатен тәмам үзенә җәлеп итте.

Топтан, матбугат чараларының һәм телевидениенең сайлаулар алды дәвердә берьяклы булып пропаганда алып баруларын тәнкыйтькә алды. «Бер айдан бирле прессаның сезнең исемегездән карар бирер ятуларына бик борчылам. Әгәр генераль секретарь һәм премьер-министрны өч гәзит һәм ике телевидение программасының хуҗалары сайлый икән, хәлебез бик авыр, димәк. Демократияне яклаган һәрбер кешене үз вазифасын үтәргә өндим. Югыйсә, әлеге хәлләрне демократия, дип атарлык түгел», дип сөйләде Топтан.

Лицейда укып бетергәннән соң, Дәмирәл белән бергә, аның янында партия һәм дәүләт иерархиясенең һәрбер, дип әйтерлек вазифасын башкарганын әйтеп үткән Топтан, XXI гасырның төрек гасыры булачагына тирән ышануын да сөйләде.

Топтан, Босния — Һерсеговина, Азәрбайҗан һәм Германиядәге кешелек фаҗигалары хакында да сөйләп, Төркиянең бөек һәм көчле булуы кирәклегенә ишарәт итте, Төньяк Кипр Төрек җөмһүриятенең дөнья тарафыннан танылуына ирешү зарурлыгы турында әйтте. Көксал Топтан нотыгын йомгаклаганнан соң трибунага менеп баскан өченче кандидат Исмәт Сәзгин делегатларны сәламләп, чыгышының шактый өлешен Тугры Юл Партиясенең тарихына багышлады: «1983 елда кечкенә бер төркем яшьләр белән кордык без бу партияне. Менә хәзер алар алдыгызда, Көксал Топтан да биредә». Исмәт Сәзгинның чыгышы делегатларның көткәненнән шактый түбән дәрәҗәле булып чыкты.

Өч кандидатның чыгышларыннан соң сайлау эшенә керешелде. Конгресска җыелган 1169 делегаттан 1114 е тавыш бирүдә катнашты һәм нәтиҗәдә икенче турда 933 тавыш белән Таңсу Чилләр җиңүче булып танылды.

АНОНС

ХУҖА ӘХМӘД ЯСӘВИ ЮБИЛЕЕНА

Мөселман төрки халыкларының рухи дөньясында, әдәбиятында гасырлар буе зур роль уйнаган, суфичылык әдәбиятына нигез салган Хуҗа Әхмәд Ясәвинең 900 еллыгына Төркиядә, май аенда Халыкара симпозиум үткәрелде. Барлык төрки-мөселман халыкларның уртак әдибе, уртак зыялысы, әсәрләре халыклашып киткән бу бөек шәхескә багышланган фәнни форумга Татарстаннан ике галимне — академиклар М. З. Зәкиевне һәм Ә. Г. Кәлимуллинны чакырганнар иде. Бу симпозиум турында язманы гәзитебезнең киләсе санында укый аласыз.

Кайсәридә реставрация эшләре

Кайсәри (Анатолия Агентлыгы). Төркиянең Кайсәри шәһәрендә Вакыфлар өлкә мөдирлеге тарафыннан бу ел эчендә 5 тарихи бина реставрацияләнәчәк. Сәлҗүк дәвереннән калган Авгунлу мәдрәсәсе, Хыдрыллэз (Хозыр Ильяс) Сарае, Хан мәчете, Томарза Олы Җамигъ мәчете һәм шәһәр үзәгендәге Сәлҗүклы төрбәләрендә реставрация эшләренә керешелде. Рәсми шәхесләр, күбесенең җимерелү алдында торган әлеге биш тарихи корылманың реставрациясе быел тәмамланып, бу эшкә 5 миллиард лира тотылачак, дип белдерделәр. Әгәр акча табылса, Гулук мунчасы, Хәйдәрбәй Сарае, Солтанханы һәм Каратайханы кәрвансарайларының да реставрация эшенә бирелүе мөмкин булыр.

Азәрбәйҗанлы рәссамның шәхси күргәзмәсе

Антолия (Анатолия Агентлыгы). Азәрбәйҗан рәссамы Рәүшән Һәмаилоглу былтыр Анатолия шәһәрендә ачып җибәргән күргәзмәсен быел яңартачак. Төркиянең кунагы булган Һәмаилоглуның рәсем күргәзмәсе Шератон Вояжер отелендә 14—18 июньдә тамаша өчен ачык.

Рәссам Рәүшән Һәмаилоглу 1954 елда Азәрбәйҗанда туды, Санкт-Петербургның Югары Рәссамлык институтын тәмамлады. Хәзерге вакытта Азәрбәйҗан Рәссамнәр Берлегенең әгъзасы булып тора.

Бразилиядә һәр ун кешенең берсендә — СПИД

СПИД авыруына дучар булган кешеләрнең саны буенча Латыйн Америкасы илләре арасында беренче урынны Бразилия били дип әйтеп узылды. Илдә һәр ун кешенең берсе кеше иммунитеты вирусын үз эчендә йөртә. Гасырыбызның иң дәһшәтле чиренә чаралар эзләнә, бөтен дөнья бу авыруның таралуын туктатырга күптөрле тәдбирләр уздыра. Статистика буенча, илдә 13 млнга якын вирус йөртүче бар, һәм кирәкле кадәр тәдбирләр уздырылмаса, авырулар санының тиз арада тагын да үсеп китеп, куркыныч саннарга җитү ихтималы бар.

Төркиянең йолдызы балкый

Англиянең мәшһүр «The Independent» гәзите «суык сугыш» беткәннең соңында Урта Азия партнерлары белән элемтәләр корып җибәргән Төркиянең йолдызы кабынуын һәм милләтара конъюктурадагы (ягъни, туар хуҗалыгының торышын билгели торган барлык шартлардагы) абруеның тиз арада күтәреләчәген язды.

Ахыры 3 биттә

Төрки блок аягына нык бассын

Гирнә (Анатолия Агентлыгы). Кипр Вакыфы белән Төрек Хезмәттәшлек һәм Күтәрелеш Агентлыгы (ТХКА) тарафыннан Төньяк Кипр Төрек җөмһүриятендә оештырылган «Төрки җөмһүриятләр арасында сәяси һәм икътисади хезмәттәшлек» темасына багышланган тугызынчы Халыкара Гирнә конференциясенең йомгаклау белдерүе игълан ителде.

Ахыры 3 биттә

Фәйзулла КАРАКУРТ

ЗОЛИНГЕНДА АЛМАН ФАШИСТЛАРЫНЫҢ ВӘХШИЛЕГЕ

УЗГАН ЕЛ Германиянең Мөльн шәһәрендә 3 төрекне тере килеш яндырган нацистлар яңадан сәхнәгә чыктылар. Германиянең көнбатышындагы Золинген шәһәрендә 29 май, төнлә төрекләр яшәгән бер йортка ут төртү нәтиҗәсендә 5 кеше һәлак булып 4 кеше авыр яраланды. Мәҗрухлар арасында 7 айлык бер бәби дә бар. Германиягә Амасия шәһәреннән килеп урнашкан Гәнч гаиләсеннән 5 яшьлек Саимә, 9 яшьлек Һүлийә, 18 яшьлек Хәдичә һәм Гөлсем Инҗә белән Гөлистан Йүксәл янып җан бирделәр. Ут төртүдән соң чыккан янгында 7 айлык сабый Борхан Дурхан, 3 яшендәге Гөлданә Инҗә һәм Бәкер Гәнч исемле төрекләрнең авыр яралануы хәбәр ителде.

Ахыры 3 биттә



ZAMAN
FARKLI GAZETE
Редакция идарәсе
Генераль директоры — **Нажи ТОСУН**

Гамәлгә куючысы —
Төркиянең ЗАМАН газите.
Хуҗасы —
Аләетдин КАЙА

«Заман»ның Татарстан мөдире —
Муаммер МУРАТ
Мөхәррир —
Рафис КОРБАН

Хәбәрләр һәм реклама бүлеге мөдире —
Мостафа ПАЛАБОЕК
Кадрлар бүлеге мөдире —
Җәгъфәр Садыйк ЧОБАНКАЙА
Тәрҗемә бүлеге мөдире — **Рәшит КАДЫЙР**
Редакциянең адресы: 420012, Казан, Декабристлар урамы, 2.
Һәр язма өчен минималь гонорар — 1 мең сум.
Язмаларны редакция белән килешүсез күчереп басу тыела.

Белешмәләр өчен телефоны: 53-34-45.
Татарстан газит-журналлар басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.
Заказ — 7000. Тиражы — 5 мең данә.
«Заман» Татарстан Җөмһүрияте мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында 246 сан белән теркәлде.
Басарга кул кую вакыты — 18 сәгатьтә.
Басарга кул куелды — 18 сәгатьтә.
Авторларның фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Мөхәммәт МӘҺДИЕВ

ФАТИХ КӘРИМИНЕҢ «ИСТАМБУЛ МӘКТҮПЛӘРЕ»

1912-13 ЕЛЛАРДА Балкан ярымутравы милли азатлык хәрәкәте белән шундагы идарәче даирәләрнең басып алу сәясәте һәм империалистик державаларның мәкерле планнары бергә төйнәлгән катлаулы сугыш аренасына әйләнә.

Балкан сугышлары вакытындагы сәяси хәлләрнең эчендә катнашу өчен «Вакыт» (Оренбург) газетасыннан мөхбир булып бу газетаның мөхәррире Фатих Кәрими Төркиягә китә. Барып төшкән көненнән үк ул үз газетасына «Истамбул мәктүпләре» дигән исем астында хәбәрләр җибәреп тора. Бу хәбәрләрендә Ф. Кәрими бик нык һәм ышанычлы рәвештә бер сәяси линия уздыра: ул — Россия дәүләте белән Төркия дәүләтенең үзара мөнәсәбәтләрендәге киеренкелекне бетерү, пантюркистлар идеологиясе белән имгәтелгән төрек зыялыларының рухында Россия халкына карата ихтирам тәрбияләү.

«Истамбул мәктүпләре»ндәге фикерләрнең иң зур күпчелеген Ф. Кәриминең мәгърифәт, мәдәният тарихы турындагы уйланулары алып тора. Ф. Кәрими төрекләрдәге мәдәният, укыту эшләренең артталыгына гаҗәпкә кала. Төркиянең икътисади, хәрби яктан артта калуын ул бары тик мәгърифәткә тиешенчә игътибар бирмәүдән дип карый, хатларында моңа кат-кат тукталa. Төрек галимнәреннән Әхмәт Мидхәтне күмү уңае белән туган фикерләре бары тик шул мәсьәлә тирәсенә генә тупланган. Әхмәт Мидхәт заманында Төркиянең зур философларыннан, мәдәният, мәгърифәт, әдәбият өлкәсендә абруйлы урын алып торган кешеләреннән берсе. Ул — язучы һәм мәгърифәтче. Г. Ибраһимов аның А. Дюма (атасы) романнарына охшатып язган «Хөсәен Фәллах» һәм «Хәсән мәллах» әсәрләренә югары бәя бирә. Гасыр башында татар яшьләре арасында Әхмәт Мидхәт, Әхмәт Расыймнарның әсәрләре яратып укылган. Ф. Әмирханның «Картайдым» хикәясендәге төп герой Мостафаның яшь вакыттагы идеалы, мәсәлән, Әхмәт Мидхәт була.... Әхмәт Мидхәтнең татарлар арасында популяр булуының сәбәбе нәрсәдә? Безнең карашыбызча, моңа Әхмәт Мидхәтнең Россиягә гомумән мөнәсәбәте төп сәбәпче булган. Бу шәхес Россия татарларының рус әдәбиятын өйрәнүләрен бик хуплаган. Фатих Әмирханның аны үз герое өчен идеал итеп сурәтләве әнә шуннан килә. Аның мәгърифәтчелек карашларына Г. Ибраһимовның биргән бәясен шулай ук искә алырга кирәк. Ул, ди, Г. Ибраһимов, халыкны укуга өндәде. Әхмәт Мидхәт госманлы төрек әдипләре арасында татарларга иң якын торган бер хөрмәтле карт иде. Әхмәт Мидхәткә рус ориенталистлары да ихтирам белән караганнар. 1911 елда Төркиядә булган вакытта А. Самойлович, Вл. Гордлевский һәм В. Смирнов аның янында булалар. Вл. Гордлевский аны «Европа мәктәбенең вәкиле» дип атый. Вл. Гордлевский «Яңа госманлы әдәбияты буенча очерклар» дигән хезмәтендә Әхмәт Мидхәт турында язып болай ди: «Әхмәт Мидхәт үзенең әсәрләре белән халыкта (әйтик, җәмгыятьтә) белемгә омтылыш уятты, ул ислам дине белән мәгърифәт арасындагы каршылыкларны алып ташларга тырышты һәм шул ягы белән ул ватандашларының гына түгел, барлык мөселманнар тарафыннан да ихтирамга лаек».

Ф. Кәрими Төркиядә әнә шул шәхесне кабергә озатуда катнаша. Әхмәт Мидхәт аның өчен дә зур шәхес булган икән. Россия өчен Толстой нинди роль уйнаса, ди Ф. Кәрими, Төркия өчен Әхмәт Мидхәт шундый рольне уйный иде. Төрекләрнең үз мәгърифәтчеләренә мөнәсәбәтен Ф. Кәрими рус җәмәгатьчелегенең Толстойга мөнәсәбәте белән чагыштыра. Толстой үлгәч рус матбугатының бу югалтуга никадәр зур урын биргәнлегенә тукталып, автор төрек газеталарының Әхмәт Мидхәт үлеменә ничек аз игътибар иткәннәренә ачына. Һәм мәгърифәтчеләрчә нәтиҗә чыгара: төрекләрнең сугышта җиңелүләре һәм гомумән артталыкларының төп сәбәбе ватаннарына хезмәт итүче шәхесләргә игътибарсыз булуыннан, ди. «Миңа бервакыт мәрхүм шәех Җәмалетдин Әфгани хәзрәтләре: «Гыйлем вә мәгърифәт каршында тез чүгеп хөрмәт күрсәтмәгән милләтнең гакыйбәте хәсрандыр (ахыр көне үкенечледер). Ул милләт яшәмәс, чөнки яшәргә лаек түгелдер»,— дигән иде. Төрекләрнең. ... Траблиста, Ямәндә җиңелүләренең сәбәпләреннән иң мөһиме берсе дә шушы, ягъни үзләренә хезмәт иткән кешеләрне тәкъдир кыйлмау вә голәмәләренә хөрмәт итмәүләре икән. Болай булгач, әле бонлар һәнүз җиңeләчәкләр икән, дидем». Әхмәт Мидхәтне күмүгә катнашкан автор, төрек зыялыларының бу вакыйгага артык салкын кан белән каравына ачына. Әхмәт Мидхәт төнлә үлә, кичкә күмәләр. Күмү процессына нибары 200-300 шәкерт катнаша. Кемне күмәсез? — дип сораганга бер шәкерт, хәтта, «белмим» дип җавап бирә. Кадимче татар хәлфәләре белем алуның иң бөек урыны, дип исәпләгән Төркиядә китапханәләрнең рәте юк, китап кадере юк. Мәгариф министры һәм баш министр булып торган Хәккый Пашаның әйтүенчә, Коръәнне тәрҗемә итү ярамый. Төрекләрнең мәдәният, фән, техника өлкәсендә артта калуларын Ф. Кәрими сугыш кырында җиңелүгә караганда да зур фаҗига итеп карый. «Мәгыйшәт мәйданы бик зур бер сугыш мәйданыдыр. «Кырык Келисә»дә, «Лүлә Бургаз»да җиңелү никадәр дәһшәтле исә, бер милләт әфрадының мәгыйшәт мәйданында җиңелүе аннан да артыграк дәһшәтледер. Ләкин бу акрынлык белән килгәнгә күрә, берден бергә күзгә күренми. Моның дәһшәтен һәркем сизмидер». Үзенең күп санлы интервьюларында Ф. Кәрими Төркиянең дәүләт эшлеклеләреннән артталыкның сәбәбен сорый. Бу мәсьәлә Ф. Кәрими мәкаләләренең һәрберсендә дә диярлек кузгатыла. Интервью вакытында Ф. Кәрими бу сорауга җавапны үзе дә эзли. «Истамбул мәктүпләре» язучының карашлары көн саен үсә, тирәнәя баруны күрсәтә торган бер әсәр. Мәсәлән, дәүләт министры Мәхмүт Әсгать белән интервьюсында Төркиянең артталыгына төп сәбәп итеп министр тарафыннан ислам дине күрсәтелә. Ф. Кәрими моның белән килешкән сыман булып яза. Ләкин алга таба ул наданлыкның социаль сәбәпләрен ачуга таба күтәрелә.

Марсель ГАЛИЕВ.

Төркия дәфтәреннән

ТӨРКИЯДӘ мин, турист сыйфатында, 1985 елда булдым. Оҗмах агачлары, оҗмах гөлләре үсә торган гаҗәеп ил. Аның табигатенә, аның кешеләренә сокланмый мөмкин түгел. Шул елны, сәяхәттән кайткач, бер бәйләм шигырьләр яздым. Истанбулның гүзәл биюче кызларына багышлап, «Төрек кызы» дигән җырны композитор Луиза Батыр-Болгари белән язган идек. Әмма радиога җырлар кабул итү комиссиясе «Төрек» дигән сүздән курыкты, үткәрмәде. Шундый чорлар бар иде бит... Без бу җырны «Шәрекъ кызы» дип үзгәртергә мәҗбүр булдык. Күңелдә юылмас ризасызлык калды. Хәзер инде аны «Төрек кызы» дип җырларга була. Бәлки, киләчәктә бу җыр Төркиянең үзендә дә яңгырар әле, дигән өметем бар.

Эгей

«Саумы!» диеп өлгермәдем,
Сау бул, Эгей дингезе»
Тауларына — зөбәрҗәт каш —
диңгезләрнең тиңсезе.

Кичке дулкыннарын гүя
ярсу сәлҗук атлары.
Давыллансаң да — син бездә
чигенер көч тапмадың.

Үрелде ак күбекләрең
төнге күк карасына.
Йолдызлар төшеп кунаклый
дулкының дугасына.

Кичен ярсыдың да, Эгей,
тынып калдың иртәнгә.
Аркадаш булып алдык та...
Безгә инде китәргә!

«Саумы!» диеп өлгермәдем,
Сау бул, Эгей, дулкындашы.
Ярны кочкан сулар кебек,
әйдә, күңел, сулкылдаш.

Бүтән инде килеп булмас,
гомер кыска. Юл озын.
Минем дә бар үз диңгезем,
күгемдә үз йолдызым.

Яңа җыр

Ой, ой, Әминә,
бармагында йөзекләр,
кулында беләзекләр,
бу нинди гүзәллекләр!
Төрек җыры.

Памуккале тауларында,
Мәрмәр диңгез буенда,
Измир күргәзмәсенең
төсле фонтан туенда,

Кая барма, бу дәртле көй
каршы алды, озатты...
Матур көйгә кемнең инде
күңеле булсын йозаклы.

Аю баскан колаклы да
куллар чабып кушылыр.
Илнең кайсы тарафына
барып чыкма — шушы җыр.

Әйтерсең лә Сара ханым*
бездән алда барган да,
язып киткән яна бер көй
бөтен халык җырларга.

* Композитор Сара Садыйкова

Әтәчкә һәйкәл

Патша чалымнары була кайчак
авылдагы безнең әтәчнең дә.
Шундый горур чөеп таҗлы башын
басып тора койма-тәхетендә.

Төркиягә баргач, шуны белдем:
дөнья базарында бик бәһале
шәп җырлый да, сугыша да белгән
әтәчләр дә бар икән бит әле.

Динизленең* шаулы мәйданында
менә сиңа һәйкәл — мәгърүр әтәч!
Җир йөзендә нинди һәйкәлләр юк,
моны күргәч, төште баштан кәпәч.

Динизледә һәйкәл куелганны
дөнья әтәчләре ишеткәндер;
Бу яңалык таулар аша килеп
безнең әтәчкә дә ирешкәндәр.

Нигә соң ул болай горур икән,
диеп йөри идем элегрәк.
Әтәчләрне дә бит аңлар өчен
кирәк икән, дөнья күрү кирәк...

* Динизле — шәһәр исеме

Төрек кызы
(җыр)

Дөньяда бер чибәрлегең син үзең дә
беләсеңдер,
беләсеңдер.
Шуңа да син күзләреңнән йолдыз чәчеп
көләсеңдер,
көләсеңдер.
Җир белән күк арасында канатланып
йөзәсеңдер,
йөзәсеңдер;
Сыгылмалы дәртле көйгә күз карашын
өзәсеңдер,
өзәсеңдер.—
төрек кызы, төрек кызы...
Сине мактап күп җырланса, барыбер син
түзәсеңдер,
түзәсеңдер.
Кайсы гөлгә тиңлим сине, бар гөлләрдән
гүзәлсеңдер,
гүзәлсеңдер.
Гүзәллеккә сокланудан яктыра җан —
күрәсеңдер,
күрәсеңдер;
Күңелләрне күңелләргә челтәр итеп
үрәсеңдер,
үрәсеңдер,—
төрек кызы, төрек кызы...

ГҮЗӘЛ СҮЗЛӘР

РИЗЫКНЫ казану хосусында йомшаклык күрсәтмә, ялкауланып ятып та Аллаһы Тәгаладән ризык сорама. Шуны беләгез: күктән алтын да, көмеш тә яумас.
Хәзрәте Гомәр (разыйаллаһу ганһи)

ЭШЛӘГӘН кешеләр ялган уйлар уйларга вакыт тапмас. Эшләмәгәннәре исә үзләрен яманлыктан коткармаслар.
Хәзрәте Гали (р. г.)

ТИК УТЫРМА, эшлә. Хакк юлда йөре вә насыйбыңны табарга иҗтиһат кыл!
Шәех Габделкадыйр Гыйлани

МИН үрләргә менәр өчен эшли-эшли төннәремне яктыр иттем.
Әбү Гали ибне Сина

Бу дөнья — хезмәт урыныдыр; хакны алыначак урыны — ахирәттер.
Имам Раббани хәзрәтләре

НЫК БУЛЫГЫЗ һәм эшләгез. Шәхси һәм иҗтимагый хәятның сере — будыр.
Мөхәммәт Икъбал

ТИК УТЫРГАНЧЫ, эшләргә кирәк. Чөнки тик утырганның гомере кичә.
Өмәр Өнгүт

МАТАШ, тук көч, уйла, эзлә, тап, йөгер, атыл, акыр.
Тик утыру заманы узды, килде эш эшләү заманы.
Тәүфыйк Фикрәт

ҺӘРВАКЫТ көч куй вә әйрән,
Эшлә, үрләргә мен!..
Әхмәт Хикмәт Муфтуоглу

Фатих КӘРИМИ

ИСТАМБУЛ МӘКТҮПЛӘРЕ

ЮЛДАН

1.

1 НОЯБРЬДӘ кич берлән Оренбургтан кузгалып киттем. Күз йомып ачканчы Самарада булдым. Фәкать күзне ачып йому гына булды, йоклап булмады. Әүвәлән, купедә дүрт кеше, бик тыгыз, һава аз иде. Җитмәсә тагын, иптәшләрнең икесе колонист немецләр улып, берсенең бөтен вөҗүде карболовый кислота исеннән гыйбарәт иде. Сонра аңлашылды ки, бу кеше немецләрнең бер хуторларында авыл фельдшеры икән.

Икенче тарафтан, Ислам вә төреклек дөньясы башына килгән фәлакәтләрне күзең берлән якыннан күреп язар өчен шул фәлакәтнең тәмам оясына таба бару вә турысын яздың исә мөселманнарның күңелләрен рәнҗетүгә мәҗбүр булу, славян дөньясындагы рухи күтәренкелек, алардагы берберсенә ярдәмнәр, утыз гына ел элек көтүчелек иткән болгарларның хәзерендә өч йөз миллион мөселманнарның мәкаме хилафәтләрен дер селкетерлек дәрәҗәгә җитүләре, Македония болгарларының фидакярлыклары вә, шуның саясендә, ниһаять, максатларына ирешүләре, Крит христианнарының һичбер мөмәнагатькә карамаенча үз матлабларына туры хәрәкәт итүләре, үзебезнең исә, дин вә кан кардәшләребезнең мәҗрүхләренә ярдәм итәрлек дәрәҗәдә килә алмавыбыз, яки шуның рәтен таба алмавыбыз, Ислам хөкемдарлары һичбер вакыт бер-берсе илә аңлаша алмадыклары хәлдә, электән бер-берсе илә дуст булмаган дүрт Балкан хөкемдарларының вә Балкан милләтләренең лөзүми вакытта дәрхаль иттифакка килүләре вә башка шуның шикелле хәлләр панорамада күренгән кебек бер-берсе артыннан күңелдән кичә, йөрәкне тырный баралар. Киткән саен үзеңне кичерәйгән күрәсең. Ниһаять, нуль булып каласың, чуалып дөньяда йөрүенә, барлыгына эчең поша башлый. Мондый вакытларда йомылган күзләр инсанга рәхәт йокы бирми, бары гасабларны бозып, газапны гына арттырадыр.

2 НОЯБРЬДӘ иртә сәгать 10да поездыбыз Самара вокзалында туктагач, иң беренче эшем башка бер урынга күчеп, немецләрнең тәнәффесне буа торган карболовый кислота исләреннән котылу иде. Монда урыннар бушаган иде. Башка бер купегә күчтем. Үзем генә идем. Тиздән янымa бер рус керде. Төз гәүдә-кыяфәтле, күңелле генә бер кеше. Дәрхаль таныштык. Мигъдә авыруын каратырга Берлинга, мәшһүр бер профессорга бара икән. Руслар безгә якын. Алар берлән тиз танышып, тиз аңлашып була. Әгәр бер такым Пуришкевич вә Милюковлар мәйданга чыгып араны ачарга хезмәт итмәсәләр, Русиядә руслар илә мөсәлманнарның бик тату, бик рәхәт яшәүләренә инанырга бер дә маниг булмас иде.

Икенче бер купедә Мәскәүгә баручы, Төркистанлы бер кардәш бар икән. Аның берлән дә танышып алдык. Сүз сугыш өстенә күчте: «Һа, бу хиффәт болгарларның хәлләре бик яман булыптыр» — диде дә, сәенечтән беркадәр көлеп тә куйды. «Ни өчен?» — дидем. «Төрекләр аларны хәйлә илә Истамбул янына китереп тә, соңра артларыннан чолгап алып, һәммә гаскәрләрен кырачаклар икән», — диде. «Бу планны Сез кайдан белдегез?» — дидем. «Йолдыз»да укыдым, «Йолдыз»да. Бу газета һәрвакыт мөселман гаскәренең җингәнен күрсәтеп яза, әмма сезнең «Вакыт» газетасы ни өчендер төрекләрнең җингәнен күрсәтми калдыра яза. Менә, Сәланиккә дә сез, греклар кергән дип, яздыгыз, әмма «Йолдыз» «кермәгәннәр» дип яза, шуның өчен без ул газетаны бик яратып укыйбыз...» — диде.

Каршымдагы бу кешенең диндар бер мөселман, хәмиятьле бер төрек икәнлегенә шөбһә юк, ләкин диянәте заһири калыптан вә хәмияте дә җаһиланә тәгассыбтан гыйбарәт икәнлеге дә күренеп тормакта иде.

(Ахыры 4 биттә)

Татарга тылмач кирәк түгел

Төрекчә сөйләшергә өйрәнүне дәвам итәбез

Саңгырау тартык авазларның яңгырау тартыкларга әверелүе

Төрек алфавитындагы p, t, c, k саңгырау тартык авазлары, сүз азагына сузык белән башланып киткән (яки бары тик бер сузыктан гыйбарәт булган) кушымча ялганса, b, d, c, ğ яңгырау тартык авазларына әйләнәләр.

МИСАЛЛАР

p

dip (төп) — dibe; dolap (шкаф) — dolaba; sap (сап) — sabın; mektup (хат) — mektubu kebap — (кәбап) — kebabı

t

inat (үҗәтлек) — inadını; kurt (бүре) — kurdu
fert (бер кеше, шәхес) — ferdin; ant (ант) — andı
dert (дәрт) — derdi

ç

taç (таҗ) — tacı; tunç (бронза) — tuncu
dönemeç (борылыш) - dönemeci; uç (оч) — ucu

k

gelecek (киләчәк) — geleceği; kabak (тирәк) — kabağı;
çelik (корыч) — çeliği; gök (күк) — göğü

ИСКӘРМӘ: nk хәреф тезмәсе ğ тартыгына түгел, бәлки g тартыгына әверелә:
renk (төс) — rengi; cenk (сугыш) — cenge
ahenk (аһәң) — ahengi; denk (тигез) — dengini

Кагыйдәдән чыгарма. Бер иҗекле сүзләрнең күпчелегендә p, t, ç һәм k тартыклары яңгырау тартык авазларга әйләнми.

at (ат) — ata; ot (үлән) — otu, ek (кушымча) — eki;

ok (ук) — oku; koç (сарык тәкәсе) — koçunu

Шундый ук күренеш башка телләрдән алынган кайбер күп иҗекле сүзләрдә дә күзәтелә:

şerbet (ширбәт) — şerbeti; merhamet (мәрхәмәт) — merhamete; sepet (кәрзин) — sepetini; hukuk (хокук) — hukuku.

Сузык авазларның сингармонизмы кануны

Сүздәге һәм аның кушымчасындагы сузык авазларның нинди төрдән булуы беренче иҗектәге сузыкка бәйле.

1. Сүзнең беренче иҗегендәге сузыклар тел арты сузыклары (a, ı, o, u) булган очракта алардан соңгы сузык авазлар да тел арты сузыклары булыр:

tarak (тарак), amaç (максат), ana (ана), durak (тукталыш), dudak (ирен), sobayı (мичне), ormana (урманга) h. б.

2. Сүзнең беренче иҗегендә сузыклар тел очы сузыклары (e, i, ö, ü) булган очракта алардан соңгы сузык авазлар да тел очы сузыклары булыр:

büyük (зур), bölüm (бүлек), böbrek (бөер), örtü (япма).

Бу кагыйдәдән чыгармалар түбәндәгечә:

а) алынма сүзләрдә аваз гармониясе кануны сакланмый: kilo (кило) otomobil (машина). davet (чакыру), hane (ханә), lazer (лазер), hançer (хәнҗәр).

б) кушма сүзләрдә шундый ук күренеш күзәтелә:

binbaşı (майор), hoşgörü (түбәнчелек, хәерхаһлык)

в) төрек асыллы сүзләрнең кайберәүләре сингармонизм кануныңа буйсынмый: anne (апа), kardeş (кардәш), elma (алма), hangi (кайсы).

г) -yor, -ken, -leyin, -ki, -tırak кушымчалары шулай ук сингармонизм кагыйдәсенә буйсынмыйлар:

getiriyor (китерә), anlatırken (сөйләгән вакытта), sabahleyin (иртән), akşamki (кичке), ekşimtırak (әчкелтем)

Дүртенче дәресне Рәшит Кадыйр әзерләде.

Бәбәрухи әкиятенең дәвамын укыгыз.

Дәвамы киләсе санда.

ЗОЛИНГЕНДА АЛМАН ФАШИСТЛАРЫНЫҢ ВӘХШИЛЕГЕ

Фәйзулла КАРАКУРТ

ВАКЫЙГА БЕЛӘН БӘЙЛЕ ХӘЛЛӘР

Полициядән алынган мәгълүматларга караганда өй тулысынча янып бетте. Янгын командасы 14 кешене коткарып калды.

Шаһитләрнең әйтүенчә, янгын чыгуга бераз вакыт кала йорт янында берничә неонацист яшьләр күренгән. Шулай ук, Золингендан килгән хәбәрләргә караганда яраланган дүрт кешенең хәле авыр.

Гомерләре өзелгән ике хатынның берсенең ялкыннан котылырга теләп тәрәзәдән сикерүе һәм шуның нәтиҗәсендә фаҗигале үлүе билгеле.

Әлеге вакыйганы тикшерүне өстенә алган Германия федераль башпрокуратурасы төрекләргә каршы булган һөҗүмнең сәяси максатлар белән эшләнгәнен фараз ителүен. Һәрхәлдә моңарчы кулга кергән дәлилләрнең шуны раславын белдерде. Шушы дәлилләрнең берсе буларак, янган йортның якынында гына урнашкан балалар бакчасында свастикаларның табылуы күрсәтелде. Полиция дә янгын чыгу сәбәбенең аңлы рәвештә ут төртү икәнен рәсми рәвештә раслады. Федераль прокурор Шталь һөҗүм итүчеләрнең үтә уң группировкаларның әгъзалары булуын сөйләде.

Янып беткән 3 катлы йортта якынча 20 төрек яшәгән. Гәнч гаиләсенең янәшәсендәге өйләрдә яшәгән алман ватандашлары ут чыгып бөтен бинаны сарып алганнан соң да янгынчыларның, үзләренә әллә ничә кат шалтыратуларына карамастан, бары тик ярты сәгать узгач кына килүләрен, эшләренә салкын карауларын әйтеп сөйләделәр.

Карлсруэ федераль прокуратурасы вәкиле Рольф Һанних исә болай иде: «Кайбер таныклар янгын чыккан вакытта шартлау тавышы ишетелгән күк булды, дип сөйлиләр, шулай ук берничә билгесез кешенең өй яныннан йөгереп качып китүен дә әйтәләр». Золинген фаҗигасенең, моннан берничә ай элек Мөльн шәһәрендә 3 төрекнең үлеменә сәбәп булган янгынны чыгаруда гаепләнгән җинаятьчеләрне хөкем итү көннәренә туры килгәненә махсус игътибар ителә. Икенче яктан, нәкъ Золингендагы һөҗүм вакытында ук, Мюнхенда да мөһаҗирләр урнашкан йортка бер баскын ясалуы һәм нәтиҗәдә 14 кешенең яралануы хәбәр ителә. Яралылар арасында төрекләрнең бармы-юкмы икәнлеге мәгълүм түгел. Бер атна элек төрек кибете һәм бер мәчет тә неонацистларның һөҗүменә дучар булган иде.

ФАШИСТЛАР БАСКЫНЫНА ҖӘМӘГАТЬЧЕЛЕК РЕАКЦИЯСЕ

Золингендагы вәхшиләрчә һөҗүмгә карата булган реакция көчәйгәннән-көчәя бара. Германия президенты Рихард фон Вайцзеккер «Ни генә әйтим соң, бик зур оялу хисе кичерәбез», диде. Премьер-министр Һельмут Коль исә Золингендагы фаҗигале вакыйга мөнәсәбәте белән Президент Сөләйман Дәмирәл һәм Премьер-министр вазифасын башкаручы Әрдаль Инөнүләргә телеграммалар күндерде. Телеграммаларда болай диелгән: «Алман халкының зур күпчелеге шушы гаять дәрәҗәдә оялырлык һөҗүм каршысында әйтәчәк сүзен таба алмый һәм бу вакыйгага карата нәфрәтен белдерә». Германия Тышкы Эшләр министры Клаус Кинкель Төркия Тышкы Эшләр министры Хикмәт Чәтингә юллаган кайгы уртаклашма телеграммасында «Бу җан өшеткеч җинаятьнең пәрдәсе артында кемнәрнең булганын тиз арада тикшереләчәген һәм һөҗүмчеләрнең кулга алынулары белән үк өсләреннән хөкем эше кузгатылачагын» әйтте.

Золингендагы фаҗига урынына килгән Төркиянең Бонндагы илчесе Онур Өймәнне жирле төрекләр каршы алып, аннан Германия хакимият органнарына мөрәҗәгать итүен, бүтән мондый хәлләр кабатланмасын өчен кирәкле чараларны күрүләрен таләп итүен үтенделәр, «без монда утка ягылып үләр өчен килмәдек! Ватаныбызда үләргә телибез!» дип кычкырдалар. Вакыйга булып үткән урынга килеп җиткән Германия Федераль Эчке Эшләр министры Рудольф Зайтерсны бер төркем төрекләр «үтерүче» дип атадылар.

Икенче яктан, президент Сөләйман Дәмирәл вакыйгага көчле протест белдерде. Вакытлы премьер-министр Әрдаль Инөнү Золингендагы төрекләргә каршы оештырылган һөҗүмнең соң дәрәҗәдә күнелләрне әрнеткеч булуын, шул ук заманда бу вакытка кадәр күрелгән чараларның канәгатьләнерлек түгеллеген сөйләде. Бөек Берлек партиясенең генераль секретаре Мөхсин Язычыоглы Золинген шәһәрендәге фаҗиганең ифрат та авыр булуын, Коль хөкүмәтенең ялгыш сәясәте аркасында Германиядә җирле һәм чит ил кешеләре арасындагы дошманлыкның арта баруын һәм шулай ук җинаятьчел баскында катнашканнарның мөмкин кадәр тиз табылуның кирәклеге турында әйтте.

ГЕРМАНИЯДӘ ЯШӘГӘН ТӨРЕКЛӘРНЕҢ ЧЫН ХӘЛЛӘРЕ

ТӨРЕКЛӘР Германиядә яшәгән чит ил кешеләренең иң зур өлешен тәшкил итә. 30 елдан бирле биредә яшәп, алман җәмгыятенең бер парчасы хәленә килделәр.

Гомумән алганда, Германиядә яшәгән чит илнекеләрнең саны 6,5 миллионга җиткән булса, шулардан сан ягыннан (1,8 миллион кеше) төрекләр беренче урынны били тора. Бу кешеләрнең яртысы Германия илендә 15 ел тирәсе яшәп яталар инде. Беренче төрекләр Алман иленә 1961 елда килә башлаганнар иде. Германиядәге төрекләр ил экономикасына ел да 70 миллиард маркалык файда китерәләр. Чагыштырыр өчен, мәсәлән, 1991 елдагы Алман илендәге тулай иҗтимагый продуктның күләме 220 миллиард маркадан гыйбарәт булган. Төрекләр һәр ел 6 миллиард марка микъдарында дәүләткә салым түлиләр, өстәвенә еллык социаль страхование өчен түләгән акчалары да 4 миллиард.

Германиядә 35 мең төрек үз эшләрен ачып җибәреп, шунда 125 мең эш урыны булдырганнар. Төрекләрнең кеше башына уртача саф килерләре 3650 марка (алман кешеләрендә 4580). Төрекләрнең 71,6 процентның өйләрендә заманча музыка җиһазлары бар, шул ук вакытта алманнарда бу сан 57,8 проценттан югары түгел. Германиядәге 81 процент төрекләр видеоҗиһазларга ия булганнары хәлдә, алманнарның бары 36,1 процентында бу җиһазлар бар. Төрекләрнең 20,4 процентында «Мерседес» маркалы машина бар, алманнарда бу сан 7,6 процент тәшкил итә.

Хәзерге вакытта Германиядә 360 мең төрек баласы укый. Болардан шактый өлеше (245 мең) башлангыч һәм урта мәктәпләрдә белем ала. 22 мең укучы лицейларга йөри. Студентларның күпчелеге хокук, икътисад белеме һәм мөһәндислек бүлекләрендә гыйлемнәрен арттыралар.

Германиядә төрекләрнең иң күп санда яшәгән урыны Берлин шәһәре. Шуннан соң тәртип белән Дуйсбург, Гельзенкирхен, Көлн, Һерне шәһәрләре килә. Бу калалар һәммәсе дә дәүләтнең индустриаль зоналарында урнашкан булып, төрекләрнең күпчелек очракта эшләгән индустрия тармаклары автомобиль ясау, корыч кою һәм металлургия. Күптән түгел фаҗигале вакыйга булып алган Золингенда төрекләр барлык шәһәр халкының 2,9 процентын тәшкил итә.

ZAMAN
FARKLI GAZETE

ТӨРКИ БЛОК АЯГЫНА НЫК БАССЫН

КОНФЕРЕНЦИЯНЕҢ генераль координаторы профессор Әрол Манисалы, йомгаклау сүзендә төрки җөмһүриятләрнең, үзара хезмәттәшлекне ныгытулары тәкъдирдә башка сәяси блоклар каршысында тагын да көчлерәк һәм мөһимрәк позицияне ала алулары хакында сөйләде. Белдерүдә, төрки җөмһүриятләрнең дөньяда тоткан урыннарын югарырак дәрәҗәгә күтәрү максат итеп куела икән, алар үзара тыгыз хезмәттәшлек мөнәсәбәтләренә керергә тиешлеге, югыйсә аерым-аерым булсалар бик авыр хәлгә төшәчәкләре хакында әйтелде. Шулай ук, Төркия белән башка төрки илләр арасындагы мөнәсәбәтләрдә мөһим хәрәкәтләр ясалган булуы белән беррәттән, моның һич тә канәгатьләндерерлек кимәлгә житмәве дә ассызыкланды. Йомгаклау белдерүе жиде маддәдән гыйбарәт. Аның төгәл текстын бирәбез:

1. Үзгәреп баручы дөньябызда төрки җөмһүриятләр арасындагы хезмәттәшлек тагын да зур әһәмияткә ия була бара. Дөньядагы башка блоклар каршысында жиде төрки җөмһүрияте дә үзара бердәмлек һәм эштәшлекләрен ныгытсалар, әлеге блоклар белән чагыштырырлык дәрәҗәдә үк позициягә урнаша алырлар.

2. Төрки җөмһүриятләрнең, булсын милләтара проблемаларны, булсын эчке проблемаларны хәл итүдә күмәк булып эшләүләре үзләренә карата башка дәүләтләрнең икеле стандарт ысулын куллануларын тоткарлый алачак. Кипр һәм Карабах шикелле низаг нокталарында төркиләрнең кыен хәлләре шушы уртак эш алып бару юлы белән яхшыртылыр.

3. Төрки җөмһүриятләр сәүдә, икътисад, сәясәт, хәрбичелек һәм мәдәният өлкәләрендә хезмәттәш була алалар. Хәзерге заманда бу хезмәттәшлеккә комачау иткән кайбер проблемалар да бар: а) төрки дәүләтләрнең бер-берсен житәрлек дәрәҗәдә танып белмәүләре; б) күчеш дәверендә булулары; в) инфраструктура мәсьәләләренең житдилеге. Әлеге проблемаларны чишү озак вакыт алачак. Иң мөһиме — төрки җөмһүриятләрнең үзара хезмәттәшлекнең үзләренә күп файда китерәчәгенә ышанулары һәм сәясәттә тәвәккәллек күрсәтүләре.

Хезмәттәшлек һәрбер төрки җөмһүриятнең мәнфәгатен тәэмин итәчәк. Уртак эшчәнлек алаңы да киңәячәк, тышкы дөнья каршысында да көч-куәте артачак.

4. Араларында уртак сәяси карашлар хасил булгач, булдыра алган кадәр башка илләрнең, Көнбатышның технологик һәм финанс мөмкинлекләреннән файдалану күләме артачак.

5. Төркия, тарихи тәҗрибәсенә таянып башка төрки җөмһүриятләрнең икътисад һәм сәясәт өлкәләрендәге үзгәртеп коруларда зур булышлык күрсәтә алыр.

6. Соңгы ике-өч ел эчендә Төркия белән төрки җөмһүриятләр арасындагы мөнәсәбәтләрдә сизелерлек бер җанланыш ар. Шулай да бу канәгатьләнерлек түгел. Яңадан-яңа чаралар күрү мәҗбүрияте көн кебек ачык.

7. Төрки җөмһүриятләр арасындагы хезмәттәшлекнең үсеше Көнбатыш белән булган мөнәсәбәтләрне алга таба үстерүгә һич кенә дә киртә булмыйча, киресенчә, аларны стимуллаштырачак.

Гирнәдә ике көн дәвам иткән конференциядә Төркия, Азәрбайҗан, Казахстан, Татарстан, Төркмәнстан, Үзбәкстан һәм Төньяк Кипр Төрек Җөмһүрияте вәкилләре белән беррәттән, Пакистан, Англия һәм АКШтан килгән галимнәр катнашты.

ТӨРКИЯНЕҢ ЙОЛДЫЗЫ БАЛКЫЙ

1989 ЕЛДА «суык сугыш» тәмамланганнан соң төрек рәсми шәхесләре паникага бирелеп, Көнбатыш алдында казанган стратегик әһәмиятләренең акча шикелле үк тиз арада кыйммәтен югалтачагы хакында уйга төштеләр, дип әйтелә мәкаләдә. Бу «кайгылы» дәвернең Гыйракның Күәйтне оккупацияләү һәм Советлар Союзының җимерелүе нәтиҗәсендә төрки җөмһүриятләрнең мөстәкыйль көч булып мәйданга чыгуы аркасында бик озакка бармавы ассызыклап белдерелә. Хәбәрдә НАТОның «Ялгыз» бер беректәш (союзник) булганда һәм дошман гарәп илләре, Иран, Греция һәм әрмәннәр белән орынып торган Төркиянең бер мәлдә төрки кардәшләре белән кавышу мөмкинлеге тууын авыр хис итүенә игътибарны юнәлтә.

«Хәзерге көндә берәр төрле сәяхәтче Берлиннән алып Мугылстанга (Монголия) кадәр төрекчә сөйләшеп рәхәтләнеп барып җитә алыр», — диелә Хью Һоуп имзасы астында басылган хәбәрдә. Автор Төркиянең йолдызы балкуының символик бер мәгънәгә ия булуын, декабрь аенда беренче төрек спутнигы «Турксат»ның орбитага чыгарылып, Балканнардан алып Себернең иң ерак почмагындагы төрки халыкларга кадәр төрекчә тапшыруларның барып җитә алачагын яза. Болай булгач, Төркиядәге 60 млн. төрек белән беррәттән, Аурупадагы 2 млн төрек эшчесе, Урта Азия һәм Азәрбайҗандагы 34 млн. төркиләр, Ирандагы 20 млн азәри һәм Кытайдагы уйгырларга үзара аралашу бик уңай булачагы ассызыкланып үтелә.

Төркиянең регионда күршеләренә арта барган йогынтысы белән халыкара мәйдандагы роле дә шуңа муафыйк рәвештә үсә. Төркия, региондагы йогынтысын, иң башта укучы-студентлар алмашуы белән арттыра. Бу көндә Төркиядә Урта Азиядән 9 меңгә якын студент белем ала. Казахстан һәм Төркмәнстан президентларының икътисад буенча киңәшчеләре — төрекләр. Азәрбайҗан сәясәтендә Төркиянең нәзарына зур әһәмият бирелә.

Төркия соңгы өч йөз ел эчендә үзенә каршы уннан артык сугыш башлаган Русиягә Урта Азиядә үзенең дә тәэсире булганын һәм аның сәясәтендә зур роль уйнавын күрсәтә.

Газетаның хәзерләгән докладында, төрки уртак базары мөмкинме, түгелме диган сорауга, Поуп, «Бу — романтик бер хыял, әмма хәзергә иң яхшысы — берләшү, киләчәктә төрки милләтләр җәмгыяте булачак» — диде.

ДӨНЬЯДА НИЛӘР БАР?

СОМАЛИ МӨСЕЛМАННАРЫНА ХАЙВАН УРЫНЫНА МӨГАМӘЛӘ

СОМАЛИДӘГЕ БМО Тынычлык Куәтләренең карамагындагы итальян солдатлары узган көннәрдә «үзебезгә ут ачтылар» дигән сылтау белән 2 Сомали мөселманын чалырга әзер булган сарык урынына җирдән сөйрәп йөрткәннәр. Корбан бәйрәме ялын өзеп Сомалига китәргә мәҗбүр булган Чәвик Паша бу вакыйга каршысында читен хәлгә төште. Чәвик Паша итальян гаскәрләре куманданы генерал Бруно Лоидән хәлне ачыклый торган җентекле рапорт бирүен таләп итте. Италия генералы солдатларының хаклы икәнлекләрен яклап сөйләп болай диде: «Без Берләшкән Милләтләр Оешмасының әмере белән вазифабызны башкарабыз. Андагылар ни дисә, шуны гамәлгә ашырабыз. Богау булмавы сәбәпле, бау белән бәйләргә мәҗбүрбез».

Итальян солдатларының Сомали кешеләренә кылган залимлекләре фотога төшерелеп исбат ителгәч, икенче бер боерык килгәнчегә кадәр вазифаларыннан алынулары хәбәр ителде. Италия оборона министры Фабио Фаббри вакыйга белән бәйле хәлләрнең тикшереләчәген вәгъдә итте.

БРАЗИЛИЯДӘ ТРАНСПОРТ ФАҖИГАСЕ

САН-ПАУЛО (АНАТОЛИЯ АГЕНТЛЫГЫ). Бризалиянең көньягында автобус, йөк машинасы һәм ике ашыгыч ярдәм машинасының бәрелешүе аркасында булган фаҗигада 33 кешенең үлеп, 35 кешенең исә яралануы хакында белдерелә.

Сан-Пауло белән Куритиба шәһәрләре арасындагы магистраль юлда дини бәйрәм сәбәбе белән ялга баручыларны йөрткән автобус йөк машинасы белән бәрелешкәч, 32 кеше үлде һәм 35 е җәрәхәтләнде. Озак та үтми, фаҗига урынына килгән ике ашыгыч ярдәм машинасы да бәрелешеп, берсенең шоферы һәлак булды.

ИРАНДА НЕФТЬ ЭШКӘРТҮ ФАБРИКАСЫНДА ДИВЕРСИЯ

НИКОСИЯ (АНАТОЛИЯ АГЕНТЛЫГЫ). Иран халкы президент сайлаган көнне, хөкүмәткә каршы булган Халык Мөҗәһитләре Оешмасының карамагындагы партизаннарның Абадан шәһәре нефть эшкәртү фабрикасына һөҗүм ясаулары хәбәр ителде.

Халык Мөҗәһитләре Оешмасы вәкиле Али Сафави биргән интервьюсында, партизаннар тарафыннан оештырылган диверсия нәтиҗәсендә фабриканың көнбатыш өлеше һавага очуын, шулай ук һөҗүм вакытында берничә «инкыйлап сакчысы»ның да һәлак булуын сөйләде.

Окан ОУЗ

Беренче морадыгыз — Тайвань!

ТӨРКИЯНЕҢ Тайвань һәм Ерак Көнчыгыш илләренә якынлашырга теләген дәлилләгән Онур Кумбарачыбашы, төрек подрядчыларына яңа морадны күрсәтте:

Апрель аеның ахырында Тайвань утравында Төркиянең сәүдә вәкиллегенең ачылачагын әйтеп узган Онур Кумбарачыбашы, дөнья экономикасының йөрәге типкән Тын Океанга китүе өчен төрек эшмәкәрләренә һәртөрле ярдәм күрсәтеләчәгенә игътибарны юнәлтте.

Төркиянең подрядчылык өлкәсендә дөнья белән ярышырлык хәлгә килгәнен белдергән Кумбарачыбашы. Бәйсез Дәүләтләр Берлегендәге (БДБ) подрядчылык эшчәнлегендә авырлыклар кичергәнен, ләкин бу авырлыкларның кыска бер вакыт эчендә үткәреп җибәрәчәкләрен алгы планга куйды.

Киләчәк 15 ел эчендә Төркия һәм Ерак Көнчыгыш арасында элемтәләрнең бик киңәеп китәчәген сораган. Планлаштыру һәм төзелеш министры Кумбарчыбашы, мин, Галатасарай лицеен зиярәт иткән вакытында балаларга француз теле белән беррәттән хәзердән үк японча һәм кытайчага да өйрәнергә киңәш бирдем», — диде.

Министр Кумбарачыбашы, Чанаккала күпере проектын подрядка кемгә тапшырылачагын шушы көннәрдә ачыкланачагын. Измир култыгында виадуклы күпер төзәчәкләрен хәбәр итте.

Министрлар кабинеты киңәшчесе Тургут Йүҗәл дә БДБдә эш корган ширкәтләрнең андагы гамәлдәге канұннар нәтиҗәсендә эш тоткарланган очракта кызыксындыру чараларының арттырачагын, ширкәтләренең һәртөрле салымнардан азат итәчәген белдерде.

Йүҗәл, хөкүмәтнең чит илләрдәге подрядчылык хезмәтләренә зур әһәмият биргәнен сөйләп, ширкәтләрнең һәм БДБ һәм Төркиягә налог түләүләрен, күчеп киткән эшчеләр өчен һәм БДБгә, һәм Төркиягә страхование премиясе түләүләрен гаять дәрәҗәдә кыен булганына басым ясап шуңа бәйле булган Льготаларны тәэмин итәчәкләрен аңыклап үтте.

Төрек-рус Совет рәисе Явуз Кылыч исә подрядчы ширкәтләренең акционерлык җәмгыятьләре акционерлар сыйфатында БДБның база икътисадына керү мәҗбүрилегенә басым ясады, ә инде кире очракта эшнең барып чыкмаячагын әйтте.

Кылыч моннан тыш ширкәтләрнең эшчеләрне Төркиядән китерелмәскә кирәклеген ассызыклап, эшчеләрне китерүнең экономик яктан кирәсез булуын жирле эшчеләрне файдалануга игътибарны җәлеп итте. Подрядчы ширкәтләренең иң зур отышсызлыгы аларның 7 мең километр ераклыктагы урнашкан объект белән идарә итү кыен булганын күрсәтеп, Кылыч, бу объектларга ачылганчы ук катгый рәвештә заманча идарә һәм оештыру кирәклеген бәян итте.

Русиядә подряд эшләрен эшләгән «МИР» Консорциумының вәкаләтле әгъзасе Җәмил Җуди Әкә исә, БДБ дәге проектларны бик күп аспектта өйрәнүен дәлилләп, үк проектларның андагыча өйрәнелмәвен күрсәтте.

Проектны тәмамлау вакытының бик мөһим булуын әйтеп узган Әкә, Русиядә кышның иртә килгәнен, бу шартларда җиһазларның кулланылмавын аңлатып бирде. Җиһазларның рус дәүләте белән килешү нәтиҗәсендә кабул ителгәнен әйтеп, Әкә вакытны югалтмас өчен төзелеш урынын ачыклауны һәм эшкә җигеләчәк җиһазларның Русия материалларын кабул итү комиссиясенә белдерелергә тиешлеген күрсәтеп китте.

Эксимбанкның генераль директоры Әхмәт Иртугрыул исә, үткән ел биш төрки җөмһүрият килешүләре төзелүен, ә аннан алдарак төзелгән мал-мөлкәт кредитының проект кредитына бик авырлык белән җайлашуын аңлатты. Бу җөмһүриятләргә бирелгән кредитларның 75 процентын инженерлык-подрядчылык хезмәтләре тәшкил итә.

АМЕРИКАНЫҢ ИКЕНЧЕ ЙӨЗЕ

ДӨНЬЯНЫҢ иң алга киткән иле АКШ, промышленность һәм технология өлкәсендә алга барган вакытта җәмгыять төзелеше рухи кыйммәтләр җәһәтеннән артка чигенә.

324 психик хастаханәдә 300 мең кеше ята, һәр ел 50 мең кеше катленәфес (үзен-үзе үтерү) итәләр һәм аерылышучыларның саны өйләнүчеләрнең санынннан күпкә артык. Американың чын йөзе — менә бу.

Дөньяда табылган бөтен нефтьнең биштән бер өлеше Америка хуҗалыгында кулланыла.

Дөньяда эшләп чагарылган наркотикларның биштән өч өлеше Америкада кулланыла.

Вьетнам сугышы Америкага 148 млрд 800 млн долларга төште. Һәм 60 мең Америка егете Вьетнам сазлыкларында ятып калды, йөзләрчә мең солдат рухи тотрыксызлык кичерде.

Америкада ун хокукчыга бер инженер, ә инде Японияне алсак, анда ун инженерга бер хокукчы туры килә.

Америкада ел саен сигез миллион кеше бер Штаттан икенче бер Штатка күчеп китә.

Америкада эшсезлек нисбәте 4 процент тирәсендә.

Америкада 120 млн машиналык автомобиль паркы бар (тулаем алганда).

Американың космик индустриясендә 1,2 млн кеше эшли.

Америка Конституциясенә 1786 елдан бирле бүгенгә кадәр 26 тапкыр үзгәртү кертелде.

Салымнарын түләмәгәне өчен, Американың отелләр хуҗасы 20 елга өтермәгә ябылды. Ул 2009 елда азат ителәчәк.

КАСПИЙ ДИҢГЕЗЕНЕҢ СУЛАРЫ КҮТӘРЕЛӘ

АЗӘРБӘЙҖАН Фәннәр Академиясендә Каспий диңгезе проблемалары буенча шөгыльләнүче профессор Абдул Касыйм Каспий суларының ике метрдан артык күтәрелүен әйтте. Диңгез суларының ике метрга күтәрелүе табигатьтә нормаль күренеш булса да, профессор әлеге су күтәрелүен тропосфераның суынуы белән аңлата.

Бу галимнең сүзләре буенча, Каспий сулары, гомумән, биш метрга күтәрелергә тиеш, һәм бу күренеш 2020 нче елга кадәр дәвам итәчәк.

Азәрбәйҗанның мең квадрат километрлы коры җирләре су астында калды инде. Ләнкарән һәм Җәлиләбад районнарындагы берничә авылны су басты, күп шосселар һәм тимер юллары, дачалар һәм санаторийлар җимерелә башлады.

Каспий суларының күтәрелүе аркасында Төркмәнстан тагын да күбрәк зыян күрә... Каспий сулары күтәрелү нәтиҗәсендә булырга мөмкин хәлләрне алдан күргән профессор А. Касыйм «Каспий диңгезен без туктата алмаячакбыз, әмма ул китерергә мөмкин зыянны алдан ук чарасын күреп кимется алырбыз, дип әйткән.

ZAMAN
FARKLI GAZETE

Мехмет КЫРКЫНЧЫ

АНАТОЛИЯДӘН ТӨРКЕСТАНГА СӘЛАМ

«ТӨРКЕСТАН» дигәндә минем күз алдымда зиннәтле һәм мөкатдәс бер күренеш гәүдәләнә. Ул бай шәһәрләрдә үсеп җиткән, галәмне соклану һәм гаҗәпләнүе белән бәя биргән күпме мөршитләрен, рухият солтаннарын, һәм тауларны күчергән, чүлләрне кичкән, авырлыкларны җиңгән ничәмә-ничә каһарманны искә төшерәм.

Йа рабби! Куенында туган, кочагында гомер иткән балаларын камиллек үрләренә, мәртәбә һәм мәгърифәткә илтеп җиткерүче нинди уңдырышлы туфрак, нәзакәтле мохиттыр ул! Җан-шәһрәтендә кояшка көндәш булырлык, илаһи рәхмәтләргә ирешкән, һәм кешелек дөньясын гыйлем-гыйрфаны белән җанландырган, һәм тугры юлга бастырып, аларны тирән гафләт (наданлык) йокысыннан уяткан, һәм җиһанда мәңге сүнмәячәк мәгърифәт утын кабызып җибәргән Гыйлани, Шаһ Нәкышьбәнди, Ясәви, Газали, Рофаи, Тафтазани, Мәүляна, Разыйлар — барчасы ул шәһәрләрнең кешелек җәмгыятенә һәдияләредер. Ул бәрәкәтле мохит Иляи Кәлимәтулла кебек бер мөкатдәс максаты, гыйшкы өчен яу чапкан Салтук-бәк, Бабуршаһ, Тугърыл-бәк, Гөндез-алып, Алып-Арыслан вә Харәзем-шаһлар кебек күпме җиһангир каһарманнар үстереп биргәндер.

Анатолия бу яшь гакылларын һәм ялкынлы дәртле каһарманнарын эчкерсез һәм алмашка берни дә алырга теләмичә, тырышлыкларын кыямәт көненә кадәр мактауга лаек һәм хөрмәт белән исенә төшерәчәктер.

Тарихның бу алтын сәхифәләрен хозурланып өйрәнеп киткәндә рухым тиңдәшсез шатлыкларга чумар иде. Мәгәр, ул затлы нәселле милләт оныкларының хәзерге көндә дәһшәтле вә катлаулы җәбер-золымга дучар ителгән калдыкларын исемә төшергәч тә, аңлатып бетермәслек моң-сагыш рухымны сарып алыр иде.

Йа рабби! Заманында ул мәмләкәтләргә гыйлем-гыйрфан, батырлык һәм гайрәт яудырган ул болытлар хәзер җаһиллек һәм фәкыйрьлек яудыралармы? Кайчандыр өстенлек уты яктысында уңышка ирешеп тәрәккый иткән ул галиҗанаб инсаннарның балалары бүген җаһиллек вә фәкыйрьлек золымы астында калганнармикәнни?! Заманында яулап алган җирләрне тетрәткән, күкрәүләре белән гарепне (шәрекъне) дер селкеткән ул корыч ихтыярлы каһарманнарының җирләрендә хәзер кемнәр бар? Ул көнҗет белән Сөмбел гөле үскән багъ вә бакчалар, ул болыннар-чирәмлекләр, ул яшеллеккә чумган далалар чүлгә әйләнеп киттемени? Гыйрфан дөньясында тирән эзләр калдырган, кешелек дөньясына дан-шөһрәт багышлаган рух, фикергә зур тәэсир ясаган ул Сәмәрканд хәкимнәренең, Бохара мөршитләренең, Бәлх суфыйларының мәдрәсәләрендә, тәккәләрендә, завияләрендә кемнәр бар?

Ислам динен хаклы рәвештә укыткан, инсаннарны җаһиллекнең тәгассебеннән (фанатизмыннан) коткарган, хорафатларның караңгылыгыннан, гыйлем вә гыйрфан яктысына чыгарган шул Мавәра-ән-нәһер (Урта Азиянең үзәге) голәмасы кайда?

Ул тере җанлы Фатихлар, Алып-Арысланнар, Кылыч Арысланнар, Бабур-шаһларга ул какшамас ихтыярын искиткеч ныклык тәрбияләгән, җиһад рухын тараткан акыл ияләре вә гыйлем әһелләре тар-мар ителдеме?! Анатолияне хәрәкәткә китергән һәм бәрәкәтләндергән ул Хөрәсан уллары һәм әүлияләры бу туфракны бөркет кебек канатлары астына алган ул Сәлҗүк-бәкләре, Каеханлылар тагы тумаячакмы?

Шуның белән бергә мин өметсез дә түгел. Ислам диненең җөелеп китүе кылыч һәм каләмнәре белән үз өстенә йөкләмә алган ул данлы, баһадир вә затлы бабаларның оныклары мәңге хөкем ителүенә рәхмәте илаһиянең булышмаячагына ышанмыйм, бу караңгы төннәрнең соңында туачагын көтәр идем.

Җәнабы хакка бинниһая хәмет вә мактау булсын ки, Аллаһның рәхмәте белән баһадир төрек милләтенең күп еллык малына, җанына, кодсиятенә каршы эшләнгән золымнарның вә җинаятьләрнең ахыры килде, ул залим һәм хурлыкка калды. Вөҗданга, кодсияткә каршы төбәлгән хакимият юк ителде. Ул зольмәтле төннәр җирен сәгадәт иртәсенә калдырып китте.

Инде сезнең өчен яңа бер тормыш заманы ачылды, һәм яңа бер галәмгә кердегез. Менә бу галәмнең, бу чорның нигезләре кайсы мәсләкләре өстенә бина ителәчәк — иң мөһим мәсьәләгез менә шулдыр.

Бу мәсләкләр иман, әхлак, өстенлек вә гыйрфандыр. Ялгыз бер шәхес һәм җәмгыятьнең гакълы шуларга килеп берегер.

Әлбәттә, нигъмәтләрнең рәхмәтлелек булганда гына яшәгәнен сез беләсез. Рәхмәтлелекне күрмәсә, нигъмәт китәр. Чөнки Җәнабы Хак сезгә иң зур бер нигъмәт булган хөрриятне бүләк итеп тапшырды. Шулай булгач, бу хөрриятне гөнаһ эш эшләүдән саклагыз. Инсан хөр булуы белән бергә Аллаһның колыдыр, өмерләрен үтәргә, тыюларыннан тайчанырга бурычлыдыр. Инсанның нә нәфсенә, нә башкасына зарар кылу юктыр. Инсанның башкаларны үтерүгә хаккы булмаган кебек, үз-үзен дә үтерү хаккы юктыр. Инсан хөррияте болар белән чикләү астына алынгандыр. Хөрриятне бу рәвешле кыйммәтләндергән тәкъдирдә ул нигъмәтләргә рәхмәтегезне кайтарган булырсыз.

Дәвамы бар.

ЙӘНИЧӘРИ КОРПУСЫ ТУРЫНДА

БУ ХӘРБИ берләшмәдә хезмәт итү мөселманнар өчен дә, мөселман булмаганнар өчен дә бөек бер мәртәбә булган. Мәгълүм булганча, Ислам кануннарынча сугыш әсирләре ганимәт (трофей) санала. Ганимәтнең биштән бер өлеше исә, Корьәннең әмере буенча дәүләт карамагына тапшырыла. Госманлы дәүләте хокукында әлеге биштән бер өлеше фарсы тәгъбире белән пәнч-йәк, халык телендә исә «пәнчек» исеме белән йөртелде.

Әхмәт АКГҮНДҮЗ

АУРУПАЛЫЛАРНЫ кызыксындырган кадәр илебездә дә бик зур кызыксыну уяткан һәм нигезе, әсасы беленмәгәнлектән төрле юрауларга дучар булган темалардан берсе — дәүширмә ысулы (ягъни Йәничәри корпусын туплау ысулы). Моннан чыгып, бу темага бәйле хокукый һәм тарихи чынбарлыкны белү зарури.

Шунысын әйтик, Госманлы төрек дәүләтендә пәнчек угланы, гаҗәми угланы йәки дәүширмә угланы исеме белән мәшһүр һәм бигрәк тә Көнбатышлылар фикеренчә, христиан гаиләләреннән балалар көчләп алынып Госманлы гаскәренә хезмәт итәргә җибәрелү һәм шулай ук әлеге балаларның сугыш вакытында үз әти-әниләрен үтерү нигезләренә корылган гаскәри оешма ул да булса Йәничәри корпусы.

Һәркем белә булыр, Йәничәри корпусы Госманлы дәүләтенең төп гаскәрендә иң көчле хәрби берләшмәсе булган һәм бу сәбәп белән Капы коллы Учаклары дигән гаскәри оешманың үзәк өлешен тәшкил иткән. Йәничәри сугышчыларының икътисади, социаль һәм идарә өстенлекләргә ия булулары сәбәпле, дәүләтнең чәчәк ату чорларында Госманлы мәмләкәтенең Йәничәри корпусында хезмәт итү һәм мөселман һәм дә мөселман булмаган һәрбер кеше өчен бик тә шәрәфле бер вазифа саналган. Чөнки дәүләтнең гаскәр һәм милек эшләрендә бөек дәрәҗәләргә ирешкән кешеләр Йәничәри Учагында җитешкән.

Госманлы дәүләтендә Йәничәри корпусын кадрлар белән тәэмин итү өчен ике мөһим чыганак булган:

1. ПӘНЧЕК УГЛАННАРЫ ҺӘМ ГАҖӘМИ УЧАКЛАРЫ

Беренче солтан Морат чорыннан алып Фатих солтан Мәхмәт заманына кадәр Йәничәри корпусын яшь егетләр белән тәэмин итү пәнчек угланнарын җыю юлы белән гамәлгә ашырылган булган. Пәнчек угланнары кемнәр соң? Аларны җыеп алу ысулы ничек булган? Моны бераз аңлатып үтик.

Мәгълүм булганча, Ислам кануннарына күрә сугыш әсирләре ганимәт санала. Ганимәтнең биштән бересе, Корьән әмере белән дәүләтнекедер. Шулай итеп, Корьән белән сабит булган бу дәүләт хакы фарсы телендә пәнҗ-йәк (1/5) атамасында йөреп, халык телендә үзгәртелеп пәнчеккә әйләнгән. Ислам хокукчылыгында сугышларда алынган, әсирләргә карата мөгамәләдә мөселман дәүләт идарәсе дүрт мөмкинлектән берсен сайлап алырга хаклы: 1) Сугыш хокукы кушканча вә Ислам динен җәелдерү максатыннан чыгып дәүләт башлыгы аларны үтертә ала; 2) мөселманнарга хезмәт итсеннәр, дип аларны кол итә ала; 3) әсирләр белән зыйммилек (зыйммы — мөселман җирендә торучы христиан йә йәһүди кешесе) килешүе төзи ала; 4) йолым (фидия яки бәдәл дип тә әйтәләр) акчасы бәрабәренә аларны азат та итә ала.

Беренче солтан Морат Ходавәндигәр, бөек хокукчы галим Рөстәм Караманлы тәкъдиме һәм Кара Хәлил Чандарлының бу эшнең шәригать кануннарына муафыйк булуын раславы нәтиҗәсендә сугышта әсир булып алынган ир-атлардан биштән бересен дәүләт хисабына гаскәр ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен алуны кануни нигезгә салып, шул заманнан ягъни Беренче Морат заманыннан башлап әлеге ысулга фарсы сүзенең ялгыш әйтелеше сәбәбе белән пәнчек җыю атамасы бирелгән. Дәүләт, хәрби хезмәткә яраксыз табылганнардан пәнчек салымы алып, яугир буларак, гаскәргә алынганнарга исә пәнчек угланы дип әйтелә башлады. Тойча дигән акынчы (баскынчы төркемнәре) гаскәрнең башлыклары тарафыннан алынган әсирләрне «пәнчекче» хезмәткәр (мәэмүр) туплый торган булган. Гаҗәми Учагының (Йәничәри корпусына керү өчен хәзерлек оешмасы) нигезен шушы пәнчек угланнар тәшкил итә иде. Бу яшь әсирләр иң элек Гәлиболуда урнашкан, соңыннан исә Истанбулга күчерелгән Гаҗәми Учакларына алынуларыннан элек, мөселман төрек гаиләләренә бирелгән. Мөселман булып, төрек тәрбиясе алганнан соң Гаҗәми Учакларында сугыш гыйлеменә өйрәнгәннәр. Гаҗәми Учакларында хәрби белем алып шуның аркасында ирекке ирешкән яшьләр гасырларча Госманлы дәүләтенең төп һөҗүм көчен тәшкил иткән Йәничәри Учагының үзәген хасил иткәннәр. Госманлы мәмләкәте, әсирләрне кол итү йә булмаса Аурупалылар шикелле сатып җибәрү урынына аларны һәм ирекка чыгарганнар һәм үзләре риза булулары тәкъдирдә Ислам динен кабул итүләрен тәэмин иткән. Шушы рәвештә пәнчек угланнарын җыеп туплап алуның бернинди көчләү яки золым белән бәйләнеше юк.

Yeniçeri askerleri

2. ДӘҮШИРМӘ ЫСУЛЫ ҺӘМ ГАҖӘМИ УГЛАННАРЫ

Солтан Йылдырым Бәязитнең Аксак Тимер тарафыннан Анкара янында җиңелүе һәм шул сәбәпле яңа җирләрне яулап алу процессының тукталуы яңа әсирләрне кулга төшерү мөмкинлеген дә вакытлыча булса да бетерде. Бу шартларда гаҗәми угланнарга булган ихтыяҗ кискен артып киткән.

Хәзерге заманыбызда өченче дөнья илләрендә яшәгән кешеләрнең, мәсәлән, Америка (АКШ) армиясендә хезмәт итү теләгендә булуларын инкяр итәрлек түгел. Шуның шикелле, Госманлы дәүләтендә иң мөһим хәрби берләшмә булган Йәничәре корпусында хезмәт итәсе килгәннәрнең (мөселман, христиан булсын) саны көннән-көн күбәйгән.

Йәничәри булып хезмәт итәргә теләүнең бер мөһим сәбәбе дә гайре мөслим (ягъни мөселман булмаган)нарның гаскәрлеккә алынмыйча, монын урынына җизьйә салымы түләү мәҗбүрилегендә калулары булган. Шул рәвешчә, бөек Госманлы дәүләтенә сокланып баккан болгар, арнаут (ягъни албан), боснияләләр һәм әрмәннәрнең Госманлы чирүендә хезмәт кылу теләкләре отыры арткан.

Шулай итеп, күрсәтелгән сәбәпләргә таянып, Госманлы дәүләте билгеле бер канун кысасында фәкать гайре мөслим булган болгар, арнаут, боснияле һәм әрмәннәрнең ризалык бирүләре шартларында һәм шулай ук анык бер кагыйдә нигезендә һәр 40 йорттан 14—18 яшьләрдәге егетләрне Йәничәри корпусына яки падишаһ сараенда мөһим вазифалар башкару өчен туплап алу эшенә керешкән.

(Дәвамы бар)

БАЛАЛАР АНАСЫЗ КАЛЫРГА ТИЕШ ТҮГЕЛ

Истанбул (Заман). ПСИХОЛОГ Суна Таналтай никахлы парларның игътибарын аерылышуның тискәре нәтиҗәләренә җәлеп итте. «Аерылышу вакытында балаларның җаннары, күңелләре сыкрый. Ир белән хатын балалары туганнан алып үсеп җиткәнче аның хәтерен бик нык сакларга тиешләр. Югыйсә, нәфес-һәвәсләренең, инстинктларының колы булулары аркасында эшләгән хаталарының бөтен өчесен балалар татый», диде Таналтай. Хөкем йортларында көн саен булып торган аерылышу процессларына шаһит Суна ханым, бу процессларның кечкенә балаларга бик каты тәэсир иткәнен һәм әлеге тәэсирнең үсмер чакларында да юкка чыкмавына ишарә итте. «Сәбәпләре нинди генә җитди булмасын, бала әтисе белән әнисенең аерылышуына беркайчан да сөенмәс», дип сүзен дәвам иттергән Таналтай никахлы парның балаларыннан түгел, бер-берсеннән аерылуларын ассызыклап сөйләде. «Хәлбүки бик күп ата кешеләрнең баладан да аерылуы күз алдыбызда. Гаиләсеннән, балаларыннан китә дә еллар буенча күренми йөри».

Суна Таналтай аерылышулардан соң баланың бары тик әтисе яки фәкать әнисе карамагында гына калу күренешен тәнкыйтьләп, баланың һәр икесенә мохтаҗ булуын сөйләде. Психолог шулай ук озынга сузылучы аерылышу эшләренең балага аеруча зарарлы йогынты ясавына да тукталып, соңра болай диде: «Баланың 5-8 яшендәге чагы бик тә әһәмиятле бер дәвер. Бу дәвердә кыз бала әтисенә, ир бала исә әнисенә ихлас күңелдән баглана. Әгәр аерылышу процессы нәтиҗәсендә мәхкәмә (суд) баланы әнисенә бирү турында карар чыгара икән, ана кеше баланың үз әтисе белән форсаты килгән саен күрешүен тәэмин итсен. Чөнки әтисе белән күрешүдән мәхрүм калган сабый өркәк, артык тартынкы булып үсәр. Мәхкәмә гадәттә 5-8 яшьләрендәге балаларны әниләре карамагына бирә. Кайвакыт бу башкача да була ала, мәсәлән, ана үз сабыен ташлап киткән очракта. Әмма ир баланы анадан читләштерү ялгыш бер гамәл. Баланың әнисен күрү мөмкинлеген тәэмин итәргә кирәк. Шулай ук ир белән хатын үз-үзләренә «Яңадан гаилә хәлендә яши алырбызмы?», «Бер-беребезне аңлап, тыныша алырбыз микән? дигән сораулар куйсалар, бәлки файдасы булыр».

Суна Таналтай ир белән хатынның аерылышканнан соң да бер-берсе хакында хөрмәт һәм сөю белән сөйләүләренең кирәклеген хәтерләргә төшерде. Бала аерым яшәсә дә, «әнием һәм әтием мине яраталар», дип әйтә алырлык булсын», диде С. Таналтай.

Доктор Сәфа САЙГЫЛЫ

Сәламәтлекнең зур дошманы: тавыш!

ТАБИПЛӘР белән галимнәр бу көндә бик күп сырхауларның сәбәбе — тавыштан килеп чыгуда дигән уртак фикердә торалар. Моннан йөз ел чамасы элек Нобель премиясе лауреаты немец галиме Роберт Кох цивилизация ачкан тавышлар хакында күрәзәчелек итеп, «Көннәрнең бер көнендә кешелек холера яисә ваба (чума) белән ничек көрәшсә, тавыш белән шулай ук көрәшеп җәфа чигәчәк»,— дигән иде.

Еллар доктор Кохның бу карашының хак булуын раслады. Табипләр бүген тавышның кешеләргә ике төрле зарар салганын беләләр инде. Тавыш ишетү сәләтенә турыдан-туры тәэсир итә.

Тавыш һәр кешене бер үк рәвештә борчымас. Монда кеше колакларының сизгерлеге һәм күңелендә булган рух халәте дә үз ролен уйный. Теләгән вакытыбызда без туктата алган тавыш, туктата алмаган тавыштан азрак гасапларыбызга (нерв) тия.

Моннан тыш, дәвамлы тавыш адреналин һормонының артуына сәбәпче була һәм моның нәтиҗәсе буларак кеше үзенең дәртен бушатырга тели. Кан тамырлары тарала, басым күтәрелә, сулу алу кыенлаша, йөрәк тагын да тизрәк кага башлый. Кеше гасабыйлана, игътибары кими, шуның өстенә иммунитеты да какшый.

Мәсьәләнең икенче игътибарны җәлеп итә торган ягы — колагыбызның цивилизация тавышларына үзен ияләштерә алмавы. Чамадан тыш сизгер булган ишетү органнарының күзәнәкләре кислородка, ягъни — кан белән яхшы тәэмин ителүгә ихтыяҗы зур була.

Колакны ял иттерү өчен шушы киңәшләрне тоту кирәк:

1) Урамга чыкканда тыныч җирләрдә күбрәк булырга кирәк;

2) Йокы бүлмәсе мөмкин кадәр тавышсыз булсын;

3) Радио һәм телевизор тавышын артык көчәйтмәскә кирәк;

4) Колакны массажлау файдалы. Ул кан әйләнешен арттыра һәм колакка тавыш тәэсирен киметә.

Фатих КӘРИМИ

Истамбул мәктүпләре

(Ахыры. Башы 2 биттә)

МИН МОНЫҢ берлән озын сүз сөйләшеп, кәкре фикерләрен турайтып маташырга лөзүм күрмәдем. Күрик инде, эшләрнең нәтиҗәсе ничек булып калыр, дидем. Ләкин үзенә: «Траблус сугышы вакытында кем җиңгән иде, ахыры ничек булып калды?» — дия кечкенә бер сөаль бирдем. «Һа, анда да төрекләр җиңеп торды» — диде. Гәрчәктән, бу кешенең «Йолдыз»ны бик ихлас берлән укыганлыгы аңлашылды. Төркистанлы бер мөселманның бер газетаны бүйлә диккать илә укуына сөендем. Ләкин, рәфикыбыз «Йолдыз»ның укучыларыны мондый хата фикерләргә төшереп калдыруына тәәссефтән үземне тыя алмадым. Ни кадәр ачы булса да вә никадәр яратмасалар да, хәкыйкатьне һәрвакыт яшермәенчә әйтә вә яза бару файдалы дип игътикад иттегем өчен, бер кыйсем халкыбызның яңадан бер кат хата фикергә төшә баруы мәэюсиятемне дәхи дә арттырды. Мәскәү, Варшауларга барып йөрүче, руслар илә катнашучы мөселман сәүдәгәр һәнүз шул фикердә болынгач, әле без һәнүз җиңеләчәкбез икән, дидем.

Сызрань вокзалында башка бер яшь мөселман илә таныштым. Мәскәүдә каракөл илә сәүдә итүче Кафкасияле Җәбраил әфәнде Касумов нам сәүдәгәр икән. Хукандтан кайтып килә. Үтәдән-бирәдән сөйләшкәннең соңында сүз тагын ук шул сугыш өстенә килде. Бу әфәнде Төркистанлыга охшамый, әхвальдән хәбәрдар. Кем җиңгәнен вә кем җиңелгәнен бик яхшы аңлый, фәкать бу җиңелүнең сәбәпләрен аңламый, шуны бик беләсе килә. Миллион ярымлык төрек гаскәренең җиңелүенә бу кеше акыл ирештерә алмый, җир йөзендәге 450 миллион мөселманның, хәтерләре аз гына булса да, игътибарга алынмауга, хосусан, башка вакытларда Төркиягә дуст күренеп килгән вә сиксән миллион мөселман тәбигагә малик булган Әнгелтәрәнең Төркияне якламавына тәгаҗҗеб итә. Ләкин, үзенең сөальләренә үзе беркадәр җавап та бирә: «Безем Ислам дөньясы башына килгән бөтен бу фәлакәтләрнең сәбәбе гыйлемсезлектер, безне шул харап итте»,— ди.

«Соң, ни өчен христиан дөньясында гыйлем бар да, бездә юк, моның сәбәбе нидер?» — дия соравыма каршы, бик мозаффаранә бер сортта вә үзенчә кәмаль канагать илә: «Бак, әфәндем, боның сәбәбе безем муллаларымыздыр, безем яшь гомерләремезне низамсыз мәдрәсәләремездә черетүчеләр — анлардыр, вә гыйлем йиренә бер такым сафсаталар илә башларымызны тутырып, хәятка истигъдадымызы бетерүчеләр кинә анлардыр Хөләсә: әвсмезе анлар ектылар. Бездә дә үйлә, Иранда, Марукта вә Төркиядә дә шүйләдер» — дия җавап бирде.

Мөселман дөньясының өе җимерелүдә ялгыз муллаларны гына гаепләү, әләбәттә, хаклык түгелдер. Өй җимерүче кешеләрне үзләренә рәис-е рухани итеп куючыларның да монда байтак гаепләре барлыгы кабил-е инкяр түгелдер. Христиан рәис-е руханиләре христиан дөньясының өен төзәтешергә ярдәм иттекләре хәлдә, җиһанның һәр тарафында, төрле кавем вә төрле нәселләргә мәнсуб булган мөселманнарның барсының да муллалары өй җимерүчеләр булуы үзе бер шаян тәгаҗҗеб эш булыр иде. Әлбәттә, мөселман дөньясының өе җимерелүдә дәхи дә тирәнрәк вә күбрәк сәбәпләр бардыр. Вә безнең бөтен аксаган урыныбызда шул сәбәпләрне кәшеф итә алмаенча гаепне берберебез өстенә аударып гомер үткәрүдәдер.

Күпедә янымдагы иптәшем рус бик күп укый, аз гына сөйләшә. Сугыш хаккында бик фәйләсуфанә мөхакәмә йөретә: «Дөнья яратылганнан бирле бит ул шулай: бер хөкүмәт бетә, икенчесе була тора, сугышлар дахи шулай искедән бирле булып килгән, булып торачак, анда хаклык вә хаксызлыкны тикшерергә урын юк, кем көчле — шул хаклы була. Төрекләргә бит Анатолиядә дә җир күп әле, әгәр игъмар итсәләр аны, җәннәт хәленә китереп рәхәт көн күрергә мөмкин»,— ди.

3 НОЯБРЬГӘ каршы Пенза вокзалыннан яныбызга бер студент керде. Мәскәү дарел-фөнүненең тарих вә әдәбият шөгъбәсен икмаль иткән. Кинә шул фәннәрне укыр өчен Германиянең Ләйпсиг дарел-фөнүненә бара. Гаять назик вә тәрбияле яшь бер егет. Вокзаллардан газеталар алып керә, ләкин сугыш вә телеграм хәбәрләрен бик аз, аннан-моннан гына карап ташлый. Фельетоннар, әдәби кыйсемнәрен башыннан ахырына кадәр укып чыга, сөйләшсә, шул турыларда сөйләшә. Бөтен күңле берлән үз мәсләгенә бирелгән гыйлем әһле. Мәсгудь вә бәхтияр бер кеше. Немецчә телне белмәсә дә, анда баргач, дүрт айда өйрәнә алачагына ышанам. Масраф өчен елга биш йөз сум житә, берьеллык акчам бар, аннары. Хода кәрим, бер рәте табылыр, ди, Яхшы күңелле бу яшь егет үзенең истикъбален, яңа чыгып килә торган кояш шикелле яктылыклар вә хәрарәтләр эчендә күрә. Хәкыйкатән, бәхтияр сәгатьләре икән.

3 ноябрьдә көндез сәгать 2ләрдә Тулага життек. Пересадка булды. Оренбургтан утырган вагоннан төшеп, Харьковка китүче поездга утырдым.

Тула, 3 ноябрь

СҮЗЛЕК

вөҗүде — тәне, **мәкам-е хилафәтләрен** — Төркия солтаны пайтәхетен, **саясендә** — артасында, **мөмәнагатькә** — каршы төшү, тыешуга, **матлабларына** — таләпләренә, **мәҗрүхләренә** — яралыларына, **лөзүми** — кирәкле, **дәрхаль** — шундук, **гасабларны** — нервларны, **тәнәффесне** — сулуны, **мигъдә** — ашказаны, **такы(й)м** — группа; набор, **манигъ** — киртә, тоткарлаучы, **хиффәт** — киләчәген уйламаучы, исәпсез, **Сәланик** — Салоники (Грециядәге шәһәр), **хәмиятьле** — башкаларның зарар китерүеннән саклаучан, **диянәте** — дин тотучылыгы, **заһири** — тыштагы, күренеп торган, **җаһиланә** — наданнарча, **Траблус** — Триполи (Ливиянең башкаласы), **гәрчәктән** — чыннан та, **бүйлә, шүйлә, үйлә** — болай, шулай; алай, **тәәссефтән** — ачынудан, **игътикад иттегем** — ышануым, **кыйсем** — төркем, **мәэюсиятемне** — өметсезлегемне, **һәнүз** — һаман (да), **болынгач** — торгач, **нам** — исем(ле), **Хуканд** — Коканд, **хосусан** — аеруча, **тәбигагә** — кулы, хакимияте астында (подданный) булган мөселманнарга, **тәгаҗҗеб итә** — гаҗәпләнә, **мозаффаранә** — җиңүче кыяфәтен китереп, **кәмаль канагать илә** — тулысынча риза булып, **низамсыз** — бер тәртипсез, рәтсез, **хәятка истигъдадыбызны** — яшәр өчен булган сәләтлелегебезне, **кинә** — янә, шулай ук, **хөләсә** — нәтиҗә, йомгак, **кабил-е инкяр** — инкарь ителергә мөмкин булган, **мәнсуб** — ...га караган, **кәшеф итә** — ача, ачыклый, **фәйләсуфанә** — философларча, **мөхакәмә** — фикер, уй, приговор, **игъмар итсәләр** — утракласалар, эшкәртсәләр, **дарел-фөнүненең** — университетының, **шөгъбәсен икмаль иткән** — бүлеген бетергән, **назик** — нәзакәтле, **мәсгүдь вә бәхтияр** — игелекле һәм бәхетле, **масраф** — чыгым, расход, **Хода кәрим** — Ходай нигъмәтләренә ирештерер, **истикъбален** — киләчәген, **хәрарәтләр** — җылылыклар, **хәкыйкатән** — (ә бит) чынлап та.